| Республика Татарстан<br>СОВЕТ<br>ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | Татарстан Республикасы<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 20 нче февраль № 18

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»19.11.2014 ел, № 14 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 19.11.2014 ел, № 14 карарына ( 29.05.2015 ел № 9; 19.06.2018 ел № 6; 20.11.2018 ел № 21; 22.02.2020 ел № 2; 07.11.2024 ел №11; 23.11.2024 ел №19/1; 16.12.2025 ел № 9; 30.12.2025 ел № 14 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«2 пунктның 2.5 пунктчасында «, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш»сүзләрен өстәргә;».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге Совет рәисе Ю.Г.Антонов